РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» март 2021ел г. Альметьевск № 281

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 08 февралендәге 212 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 31 декабрендәге 1097 номерлы, «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карарлары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 08 февралендәге 212 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018

Зак. № 305-2000

елның 11 июлендәге 962 номерлы, 2020 елның 14 декабрендәге 1838 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карага 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

««Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән»;

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Идарә башлыгына түләү чыгымнарын финанслау район бюджетын үтәү барышында өстәмә алынган керемнәр, ел башына район бюджеты счетында калган акчалар, бюджет чыгымнарының аерым статьялары буенча ассигнованиеләрне яңадан бүлгәндә алынган буш лимитлар хисабына башкарыла»;

2 бүлекнең 1 пунктындагы 1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Табл.№ 1

| № п/п | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | Идарә башлыгы | 18248 |
| 2 | ЕДДДС җитәкчесе | 7724 |
| 3 | Оператив дежурный | 7028 |

3 бүлекнең 3 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен айлык өстәмәләр - Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән күләмнән һәм тиешле елга җитештерү календаре нигезендә эш көне булмаган бәйрәм көннәре саныннан чыгып;».

2. Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) район бюджетын үтәү процессында өстәмә алынган керемнәр, ел башына район бюджеты счетындагы акчаларның калган өлеше, район бюджеты чыгымнарының аерым статьялары буенча ассигнованиеләрне яңадан бүлгәндә алынган буш лимитлар исәбеннән Идарә башлыгына түләүләрне финанслауны күздә тотарга тәкъдим итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2021 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов